Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы

# Рус мәктәпләрендәге рус төркеме укучыларына татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең ДӘҮЛӘТ СТАНДАРТЫ

Казан
2005

## Кереш.

Рус мәктәпләренең рус төркеме укучыларына татар әдәбияты 1992 нче елдан татар теле белән бергә кушылып (интеграцияләп) өйрәтелде. Соңгы елларда башлангыч мәктәптә уку дәресләре, 5-11 нче сыйныфларда татар әдәбияты экспериментальь программалар белән аерым фән буларак укытыла. Рус төркеме укучыларына татар әдәбиятыннан гомуми белем бирү дәүләт стандарты бу үзенчәлекләрне истә тотып төзелде.

Рус төркеме укучыларына татар әдәбиятын укытуны тулаем гамәлгә кертү процессында өч елдан соң дәүләт стандарты яңартылачак.

## Гомуми башлангыч белем бирү мәктәбе
## (1 нче баскыч – I–IV сыйныфлар)

Әдәби укудан гомуми башлангыч белем бирүнең

**максатлары**:

1) татар теле дәресләрендә алган белемнәрне әдәби әсәрләр уку аша ныгыту, сөйләмдә куллану, укучыларның татар телендә аралашу мөмкинлекләрен үстерү;
2) татар балалар әдәбиятының күренекле язучылары , аларның иҗаты белән таныштыру;
3) татар телендә укуга кызыксыну уяту, әдәби уку тәҗрибәсе булдыру, әдәби зәвык тәрбияләү;
4) укучыларда әхлакый - эстетик сыйфатлар, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык хисләре тәрбияләү.

## Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы

**Китап уку эшчәнлеге**. Әдәби һәм фәнни популяр әсәрләр, татар халык авыз иҗаты әсәрләре. Татар әдәбиятының күренекле язучылары әсәрләре,



- рус һәм татар телендәге әсәрләрнең уртак һәм милли үзенчәлекләрен билгеләү, әхлакый кыйммәтләрне чагыштырып бәяләү;
- татар һәм рус телендәге әсәрләргә телдән һәм язмача фикерен белдерү, аларга бәя бирү;
- татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
- диалогта яисә бәхәстә катнашып, үз фикерен исбатлый белү.

- төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку;
- сәнгатьле уку;
- кабатлап сөйләүнең төрләре;
- шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан өйрәнү;
- укыган әдәби текстның төрен һәм жанрын билгеләү;
- автор позициясен, геройларның теге яки бу эш-гамәленә нигез булган мотивларны һәм конфликтның асылын ачыклау;
- бәхәсләрдә катнашу, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларын раслау һәм дәлилләү;
- рус һәм татар телендәге әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләү;
- рус телендәге әдәби текстларны татарчага һәм киресенчә тәрҗемә итү.

## Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр

Укучы туплаган белем һәм өйрәнгән күнекмәләр:

- татар әдәбиятының дөньякүләм тоткан урыны, татар әдәбияты классиклары, аларның әсәрләре турында мәгълүмат;
- сүз сәнгатенең образлы табигате турында;
- өйрәнгән әдәби әсәрләрнең эчтәлеге;
- классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактлары;
- төп әдәби-теоретик төшенчәләр;
- әдәби әсәрнең эчтәлеген сөйләп аңлату;
- әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләү;
- әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләү;
- автор позициясен ачыклау;
- әдәби бәйләнеш таләпләрен саклаган хәлдә өйрәнелгән әсәрләрне (яисә өзекләрне) сәнгатьле итеп уку;
- укыган әсәргә дәлилле рәвештә үз мөнәсәбәтең белдерү;



(Г.Тукай, Дәрдеменд, М.Җәлил, А.Алиш, Б.Рәхмәт, Ә.Бикчәнтәева, М.Фәйзуллина, Ш.Галиев, Р.Миңнуллин, Р.Вәлиева, Ф.Яруллин,) балалар әдәбиятының дөньякүләм танылган классиклары әсәрләре, төрле энциклопедияләрдә, белешмә-сүзлекләрдә һәм балалар өчен басылган вакытлы матбугатта бирелгән материалларны уку.

**Балаларга уку өчен тәкъдим ителгән әсәрләрнең төп темалары**: туган тел, табигать, хезмәт, балалар тормышы, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре, гаилә, сәламәтлек саклау, яхшылык һәм яманлык.

**Әдәби әсәр эчтәлеген аңлауга мөнәсәбәтле үзләштерелергә тиешле мәсьәләләр**: әсәр темасы, төп фикере, вакыйгалары һәм аларның эзлеклелеге. Әсәр герое, аның характеры, гамәлләре, гамәл кылырга этәргән сәбәпләр. Геройның эмоциональ һәм әхлакый кичерешләрен аңлау, кабул итү. Рус һәм татар әдәбияты геройларын үзара чагыштыру. Әкиятне һәм кече фольклор жанрларын, автор әкиятләрен, хикәя, шигырь, мәсәлләрне әдәби жанр буларак аера белү.

### Әдәби укуның һәм аралашуның төп темалары.

Туган як.

Табигатьтәге үзгәрешләр.

Табигатьне саклау.

Көндәлек режим.

Уку хезмәте.

Ял вакыты.

Өлкәннәргә булышу.

Олыларга, кечеләргә мәрхәмәтле, шәфкатьле булу.

Бәйрәмнәр.

Дуслык, туганлык мөнәсәбәтләре.

Әдәби әсәрнең эчтәлеге, төп темасы. Әдәби герой.

Әдәби әсәрләрнең төп жанрлары: әкият, хикәя, шигырь, табышмак,

мәкаль, әйтем, җыр.
Классик балалар әдәбияты авторлары турында кыскача белешмә
(Г.Тукай, М.Җәлил, Р.Батулла, А.Алиш, Р.Миңнуллин).

**Сөйләм эшчәнлеге.**

**Ишетеп аңлау.** Таныш материалга нигезләнгән сөйләмне аңлау, татарча җанлы сөйләмне тыңлап, җөмлә, сүз чикләрен билгеләү, сөйләм барышында эчтәлеккә төшенеп бару; кирәкле мәгълүматны аерып, сорауларга җавап бирү; сорау кую; эчтәлекне татарча яки русча сөйләп бирү.Укытучының уен, дәрес ситуацияләре белән бәйле сорауларын , күрсәтмәләрен аңлау.

**Уку.** Таныш материалга нигезләнгән кечкенә күләмле текстларны аңлап уку, сүзләргә, кыска җөмләләргә дөрес басым кую, тиешле интонация белән уку. Таныш материалга нигезләнгән кечкенә күләмле текстларны, шулай ук беркадәр күләмдә таныш булмаган сүзләр кергән текстларны эчтән аңлап уку, кирәкле мәгълүматне табу. Сүзлекләрдән файдалана белү.

**Телдән сөйләм.** Кече яшьтәге мәктәп балаларының аралашу сфераларына һәм тормыш ситуацияләренә туры килгән диалогик сөйләм оештыру. Укыган әдәби текстның кыскача эчтәлеген сөйли белү, әсәрдәге вакыйгаларга, геройларга карата үз фикерен белдерү. Сөйләм этикетына караган сүзләр: исәнләшү, саубуллашу, танышу, гафу үтенү, үтенеч белән мөрәҗәгать итү, котлау, рәхмәт әйтү һәм кайтарып сорау, сораша белү, эш кушу яки өндәү, ризалык яки ризасызлык белдерү үрнәкләрен дөрес һәм урынлы кулланып сөйләшү оештыру.

Шигырьләрне яттан өйрәнеп, дөрес итеп сөйли белү.

Үзенең һәм яшьтәшләренең эшчәнлеге; әйләнә - тирә мохит турында, үзенең мөнәсәбәтен белдереп , бәйләнешле сөйли белү.



2) гуманлык карашлары, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, татар әдәбиятына һәм татар халкының мәдәни кыйммәтләренә ихтирам тәрбияләү;

3) әдәби зәвыкны, телдән һәм язма сөйләмне үстерү;

4) татар классик әдәбияты, балалар әдәбиятының, хәзерге татар әдәбиятының күренекле вәкилләрен атый белү, аларның әсәрләреннән өзекләрнең эчтәлеген аңлау һәм фикер алыша белү.

Татар халкының әдәбияты, тарихы, мәдәнияте буенча мәгълүматлы булу.
Бүгенге татар сәнгатенең күренекле вәкилләре турында хәбәрдар булу.

## Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы

Халык авыз иҗаты үрнәкләре: әйтемнәр, мәкальләр, сынамышлар, бәетләр.

Сүз сәнгатенең барлык жанрларына да кагылган әсәрләрдән (хикәя, шигырь, поэма, повесть, роман) өзекләр:
Кол Гали, Г.Камал, К. Тинчурин, Һ.Такташ, М.Гафури, М.Җәлил, Г.Кутуй, Ф.Әмирхан, М.Әмир, Ә.Еники, И.Гази, Н.Дәүли, Г.Әпсәләмов, Х.Туфан, Г.Мөхәммәтшин, Н.Фәттах, М.Мәһдиев, Г.Ахунов,Ф.Хөсни, И.Юзеев, Ш.Маннур, Г.Сабитов, С.Хәким, Ш.Рәкыйпов, Ф.Яруллин, М.Насыйбуллин, Т.Миңнуллин, Г.Әхтәмова, Х.Вахит, М.Хәсәнов, Р.Гаташ.

Татар халкының сәнгате, тарихы, мәгърифәт үсешен чагылдырган информацион материаллар.

Прагматик һәм эпистоляр жанр текстлары.

**Төп эшчәнлек төрләре**

Тарихи-иҗтимагый мәдәни вакыйгаларның әдәбиятка йогынтысы. Реалистик әдәбият үсеше. Тема-мотивларның, жанрның төрлелеге,

- татар һәм рус әдәбиятындагы әсәрләрне чагыштырып, үз фикерен әйтә белү;

- рус телендәге әдәби текстларны татарчага тәрҗемә итү.

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр.**

Татар әдәбиятының күренекле язучылары һәм шагыйрьләре, аларның әсәрләре турында мәгълүмат булдыру.

Әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес, йөгерек, сәнгатьле уку. Уку тизлеге нормаларын үтәү. Укыганның эчтәлеген өлешчә, яки тулы аңлап бару, укыганда сүзлекләр куллану. Укыганнан кирәкле информация таба белү. Укыганга план төзи белү. Әсәрнең эчтәлегендә яктыртылган проблемаларны аңлый белү, ул проблемалар буенча үз фикерләрен әйтә белү. Әсәрдәге геройларны характерлый белү, алар турында үз фикерен әйтә белү. Әсәрнең авырлыгына, катлаулылыгына, күләменә карап, кыскача яки тулы эчтәлеген сөйли белү. Әсәр эчтәлеге буенча диалогик сөйләмдә катнашу, сорауларга җавап бирү.

Аерым автор, аның әсәре, гомумән, әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары аша таба белү.

**Профиль дәрәҗәсе.**

**Гомуми урта (тулы) белем бирү мәктәбе**

**(3 нче баскыч – X-XI сыйныфлар)**

Татар әдәбияты өйрәнүнең

**максатлары.**

1) Матур әдәбият текстларын кабул итү, төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне белү; әдәби-тарихи процесс турында гомуми караш булдыру;



**Язу.** Басма тексттан сүзләрне һәм җөмләләрне дөрес күчереп язу. Үзе, гаилә, мәктәп, ел фасыллары турында кечкенә күләмле хикәя язу.

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр.**

Татар балалар әдәбияты турында мәгълүмат булдыру.

Әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес, йөгерек, аңлап, сәнгатьле уку. Уку тизлеге нормаларын үтәү.

Аңлап эчтән уку.

Укыганның эчтәлеген өлешчә, яки тулы аңлап бару, укыганда сүзлекләр куллана белү, укыганның эчтәлеген сөйли белү.

Укыганда кирәкле информацияне таба белү.

Үзе укыган текст буенча 4-5 җөмләдән торган хикәя яза белү.

Татар халык авыз иҗаты әсәрләре: мәкаль, әйтем, табышмак, экиятләрдән мисаллар китерә белү.

Программада ятлау өчен тәкъдим ителгән әсәрләрнең кимендә дүртен яттан хәтерләү.

**Гомуми төп белем бирү мәктәбе**

**(2 нче баскыч – V–IX сыйныфлар)**

Татар әдәбиятыннан гомуми төп белём бирүнең

**максатлары:**

1) татар әдәбияты әсәрләрен өйрәнү аша татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүнең сыйфатын яхшырту;
2) укучыларның телдән һәм язмача аралашу мөмкинлекләрен киңәйтү;
3) татар әдәбиятының алтын хәзинәсен тәшкил иткән әдәби әсәрләр белән таныштыру;
4) гомумкешелек әхлакый сыйфатлар тәрбияли алырдай әсәрләр аша укучыларның татар телен өйрәнүгә кызыксынуларын арттыру;

5) авторларның иҗаты, тормыш юлы турында кыскача белешмә бирү, төрле сәнгать вәкилләре белән танышу;
6) газета - журналлардан мәкаләләр, информацион характердагы материаллар белән танышу.

## Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы

Татар әдәбиятын өйрәнү өчен эчтәлек сайлау әдәбият белемендә кабул ителгән эстетик һәм әдәби принципларга бәйле.

Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре: әкият, җыр, табышмак, мәкаль әйтем, сынамыш, тизәйткечләр.

Төрле әдәби жанрлардагы әсәрләрдән (хикәя, повесть, роман, драма), әхлакый проблеманы үз эченә алган өзекләр;

К.Насыйри, Дәрдмәнд, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Гафури, Г.Гобәй, С.Хәким, Һ.Такташ, М.Җәлил, Ф.Кәрим, А.Алиш, Г.Кутуй, Н.Дәүли, М.Садри, Ә. Фәйзи, Ә.Еники, Г.Бәширов, Г.Әпсәләмов, Ф.Хөсни, Ш.Маннур, Г.Афзал, И.Гази, Ә.Баянов, М.Мәһдиев, Р.Ишморатова, Ф.Яруллин, Ш.Галиев, Б. Рәхмәт, Р.Миңнуллин, Р.Мингалим, М.Галиев, Җ.Тәрҗеманов, З.Туфайлова, Р.Вәлиева.

Биографик белешмәләр: Һ.Такташ, А.Алиш, Д.Аппакова, Т.Миңнуллин, Р.Миңнуллин, Ш.Маннур, Ф.Хөсни, Л.Ихсанова, М.Мәһдиев, Р.Вәлиев, К.Насыйри, Г. Тукай, Г.Ибраһимов, Н.Дәүли, М.Гафури,С.Хәким, Ә.Еники, Ф.Яруллин;

– башка милләт әдәбияты үрнәкләре;

– прагматик текстлар (рецептлар, радио, телевидение программалары, белдерүләр)

– эпистоляр жанр текстлары (шәхси һәм официаль хатлар, котлаулар).



### Әдәби уку һәм аралашу өчен төп темалар.

Уку хезмәте. Китап һәм белем. Белем һәм тормыш, һөнәрләр дөньясында.

Гаиләдә өлкәннәр һәм кечкенәләр мөнәсәбәте, өлкән буынга хөрмәт, уртак хезмәттә үз өлешеңне күрә белү , балаларның мөстәкыйль хезмәткә тартылуы.

Хезмәткә хөрмәт. Кеше хезмәтен хөрмәтли белү . Икмәккә хөрмәт.

Яшьтәшләр, яшүсмерләр, алар арасындагы мөнәсәбәтләр; аларның проблемалары. Малайлар, кызлар мөнәсәбәтләре.

Буш вакытны дөрес файдалану. Яшүсмерләрнең шөгыльләре, ялны дөрес оештыру проблемалары.

Әдәплелек, үз- үзеңне матур тоту кагыйдәләре. Бүгенге яшьләрнең әдәплелек турында күзаллавы.

Дуслык. Чын дус булу проблемалары.

Табигать . Экология проблемалары. Табигать һәм кеше.

Дүртаяклы дусларыбыз. Аларга мәрхәмәтле булу.

Татарстан - туган ягым. Татарстанның сәнгать вәкилләре, күренекле татар язучылары һәм шагыйрьләре.

Милли бәйрәмнәр , татар халкының традицияләре.

### Төп эшчәнлек төрләре

- төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку;
- сәнгатьле уку;
- кабатлап сөйләүнең төрләре (тулы итеп, кыскача, сайлап);
- шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан өйрәнү;
- план төзү һәм әсәрләр турында кыскача бәяләмә (отзыв) язу;
- сочинение элементлары белән изложение язу;